**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ МОНАСТЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422392, Республика Татарстан,
Тетюшский район, с. Монастырское,
ул. Комсомольская, д. 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422392, Татарстан Республикасы,
Тәтеш районы, Монастырск авылы,
Комсомол урамы, 33

Тел. (84373)5-45-20, факс: 5-45-20, e-mail: monastyr.tetushi@tatar.ru
ОКПО 92655464, ОГРН 1021606556883, ИНН/КПП:1638001649/163801001

# КАРАР

**26 февраль 2020 ел** **№ 57-3**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы 2010 елның 26 октябрендәге 2-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы 2010 елның 26 октябрендәге 2-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктындагы «торак төзелеше өчен (бирелгән)» сүзләреннән соң «(эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» дигән сүзләрен өстәргә»;

2) 2 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук Федераль законда каралган «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы карарында каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,15%»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган мәгълүмати стендлар аша халыкка җиткерергә, Тәтеш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://tetushi.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге башлыгы А.А. Васинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Монастырск авыл җирлеге**
**башлыгы** **А.А. Васин**